Хәмидуллина, Р. Өй күрке – мич : [хикәя] / Р. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 8 (6 февраль). – Б. 20.



**ХИКӘЯ**

Роза Хәмидуллина

# ӨЙ КҮРКЕ – МИЧ



Telegramда безнең төркем **shahrichally**

ВКонтактеда безнең төркем **shahrichalli**

Одноклассникида безнең төркем **shrichally.gazetasy**

– Мич тузды, балалар, яңаны салырга кирәк. Камырым – камыр түгел, өсте килсә, асты килми, асты килсә, өсте юк... Булды, башка интекмим, быелгы җәйдән дә калу юк. Үзем исән чагында, шушы кечкенә тәмле тамакларыма кабарып, кетердәп торган кайнар камыр ризыкларын ашатасым килә.

Тәмле тамаклар дип оныкларын атый Мәдинә. Оныкларга бай, Аллаһка шөкер. Беренче оныгы Айраты да инде әти булды. Әле унтугызын яңа гына тутырган игезәк сыңары Лилиясе кияүгә чыгарга йөри. Бәхете генә була күрсен инде балакаемның, дип, киң итеп сулыш алып куйды. Игезәкләр алып кайтып сөендерде киленнәре, рәхмәт төшкерләре. Ике улының да игезәк кызлары бар. Аның белән төп йортта яшәүче игезәк оныклары Алия белән Алинә дә, инде кул арасына кереп, булыша башладылар. Әй-әй-әй уйласаң, уйлап утырырга сәбәпләр күп. Бай оныкларга – унау бит алар хәзер. Әй кечкенәрәк чакларда җәй көне өелешеп кайтып җитәрләр иде, түзеп кенә тор инде, мин сина әйтим. Ипине сатып алып өлгереп булмый, әле салып пешереп җитешсәң дә чамага гына туры килә иде. Ә хәзер өелеп кайтулар сирәгәйде.

– Балаларының йә уку, яисә имтихан вакытлары дип, уллары-киленнәре үзләре генә кайтып китәләр. Улларга бай булды Мәдинә: дүрт ул, бер кыз бала тапты. Әниләрнең бәхете балаларның матур, тату, тигез яшәвендә инде. Һәрбер намаз саен улларын-кызларын догасыннан калдырмый. Әхәтенә генә менә оныкларның уңышларына сөенеп яшәргә туры килмәде. Бигрәкләр дә яшьли китеп барды инде мәрхүм.

Уйчанланып басып торган Мәдинәне төпчек улы уйларыннан бүлде:

– Мич тузды дисең инде ә, нигә кирәк инде хәзер өйгә мич? Газ бар әнә, пешерегез күпме кирәк? Өй уртасында мич утырмаса, өйдә урын киңәеп китәр иде, тузаныннан да бераз котылыр идегез.

Сүзне коры йөртергә уйлый төпчек улы. Мәдинә дә бирешә торганнардан түгел анысы.

– Газ, дисеңме? Аллаһка шөкер, газ бар-барын, рәхмәт. Ләкин мичтән әлегә котыласым юк. – Мин киткәч чистартырсыз, киңәйтерсез өегезне, – диде, кулларын зират ягына чөеп күрсәтеп. Аннан аяк астында йөрүче оныклары янына чүгәләде. – Әлегә мич миңа түгел, менә боларга кирәк, мичне бетерергә рөхсәтем юк.

Әни сүзе закон. Башка сүз куертып тору кирәк түгеллеге аңлашылды.

Икенче көнне үк зур эшкә тотынырга булдылар. «Ломать – не строить», ди урыс халкы. Килен, кода, кияү – барысы да эштә булды. Өйлә якынлашканда мич сүтелеп тә беткән иде инде. Бигрәкләр дә кара эш, ул мичтән чыккан корым, түзеп кенә тор. Чыгар да шул кара корым...

– Динә туган елны өйне салдык, мичне дә шул елны чыгардык. Әтиегез күрше Норлат авылыннан мичче алып килде, – дип сөйләнде Мәдинә. Шактый үк еллар үткән икән ләбаса. Ә ул Динәсенә һаман бала итеп кенә карый.

Чынлап та уңган иде ул әлеге мичтән. Тәмле итеп кыздырып пешерә иде миче. Кайвакытларда эш белән мавыгып мичен онытса:

– Юк, монысы булмады, бигрәкләр дә көеп китте, – дип сөйләнә башлый Мәдинә.

Моны ишеткән Әхәте:

– Балалар ашыйлармы соң? – дип сорар иде.

– Ашыйлар, чыгарып кына өлгер.

– Балалар ашагач, булган инде алайса, балалар тәмсез әйберне бик тиз сизәләр алар, дип, мыек астыннан гына кеткелдәп көлеп алыр иде бәгырь.

Дәвамы бар